Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының егерме тугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

29 декабрь, 2022 ел № 208

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Питрәч - Чыты - Янсуар» - Талкыш автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты буенча ызанлау проектын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын тотуның һәм үстерүнең төп идарәсе» ДКУ мөрәҗәгатен исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Питрәч - Чыты - Янсуар» - Талкыш автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты буенча ызанлау проектын кушымта нигезендә үзгәрешләр кертмичә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль район башлыгы И.М. Кашапов